# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**03.12.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 03 декабрендә 13:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (МТЗ-82 тракторы өчен запчастьләр, асылмалы һәм тагылма җиһазлар сатып алу; дизель ягулык һәм майлар сатып алу).
2. Нарат торак пунктында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссель, фонарьлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү.
3. Нарат торак пунктында су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм материаллар сатып алу, ремонтлау, хезмәт күрсәтү, башка хезмәтләр күрсәтү.
4. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм янгын сүндерү машинасы йөртүче хезмәтенә түләү

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 119 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 65 кеше, бу 54,6 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 65 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (МТЗ-82 тракторы өчен запчастьләр, асылмалы һәм тагылма җиһазлар сатып алу; дизель ягулык һәм майлар сатып алу).

2. Нарат торак пунктында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссель, фонарьлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү.

3. Нарат торак пунктында су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм материаллар сатып алу, ремонтлау, хезмәт күрсәтү, башка хезмәтләр күрсәтү.

4. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү: ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм янгын сүндерү машинасы йөртүче хезмәтенә түләү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.М. ЙОСЫПОВ